РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
СЕМЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СИМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423989, Р.Т. Муслюмовский район, с.Семяково, ул.Школьная д.8а*
Sem.Mus@tatar.ru *тел. (8-85556) 3-33-16*
ИНН 1629003953, КПП 162901001, ОГРН 1061687005181, ОКАТО 92242865000.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
№ 5 05.03.2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Симәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Симәк авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 февралендәге 2 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибенә түбәндәгеләрне өстәп, үзгәреш кертергә:

**1.1. 10 пунктның 2 абзацын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән дәвам итәргә:** «һәм мәҗбүри рәвештә салым, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булмау турында Россия Федераль салым хезмәтеннән белешмә.».

**1.2. 10 пунктны 3 абзац өстәргә:** «мөрәҗәгать итүче 10 пунктның 2 абзацында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, җирле үзидарә органы ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмәләрне мөстәкыйль рәвештә соратып ала».

**1.3. 20 пунктны түбәндәге 4 пунктча белән тулыландырырга:** «4) законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе:** **Садертдинов Р.Ә.**